

Чаян

ISSN 0136-7110

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * НОЯБРЬ * 2017 * КАЗАН 11



АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

• Трамп Төньяк Кореяны яңадан демократия белән куркыта башлады.

• Украинаның Куркынычсызлык советы Порошенкога каршы оештырылган һөҗүмне булдырмау турында хәбәр иттеләр. Горилка шешәсе кулга алынган.

• Рәсәй, Кырым өчен компенсацияне 200 сумлык акчалар белән түләргә әзер булуын белдергән.

• Амстердамда көлүче малай статуясын куйганнар.

• Актриса Вупи Голдберг, продюсер Харви Вайнштейн кочламаган бердәнбер хатын булып калган.

• Компьютер клавиатурасын сөртеп йөрүче җыештыручы ялгыш Австриядәге сайлау нәтиҗәләренә йогынты ясаган.

• Озон тишеген өйрәнүче Рәсәй галимнәре, бу эшләрен ташлап, Пенсия фондындагы тишек-тошыкларны өйрәнергә керешкәннәр.

• Аракы заводын кулга төшергән террорчылар инде атна буе үзләренең таләпләрен аңлата алмый интегәләр.

• Комбайнчыларның акча алган көнендә киң кырларда серле түгәрәкләр барлыкка килгән.

• Юл хуҗалыгы фәнни тикшерену институтында автомашиналар өчен куркынычсыз булган ачык канализация коелары эшләнгән.

• Илдә беренче криптовалюта фахишәләре барлыкка килгән.

• Голливудта "Вайнштейн исемлеге" дигән фильм төшерә башлаганнар.

• Автобустагы "куян", түләү мәсьәләсендә тавыш куптарып сугыша башлаганнан соң, кондуктор белән уртак фикергә килгәннәр.

• Экономистлар исәпләвенчә, әгәр бер кеше, файдалы эш белән шөгыльләнсә, ул тагын өч эш урынын барлыкка китерә: күзәтеп торучы, икенчесе – комачаулаучы, өченчесе – өйрәтеп торучы.

• Ялган сантехникларга суд башланды. Алар, пенсионерларның фатирларына кереп, акча сорамыйча гына бушка ремонт эшләре башкарган.

• Табиблар, көзге депрессиядән иң яхшы дәва дип, көзге хәрби чакырылышны таныганнар.

• Һава торышын билгеләүчеләр, быелгы кышны җәйдән һәм хәтта көздән дә суыграк булачак, дип фаразлыйлар.



Михаил ФРОЛОВ



ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел бөтенебезгә таныш Ксения Собчак күңелебезне ачты. Сары чәчле яшь ханым... Россия президенты булырга теләве турында белдерде. Бу шаяртудыр бит?

Л. ВӘЛИЕВА

ӘГЕРҖЕ

– Әлбәттә, шаярту, – диде Шомбай ага, хатны укып чыккач. – **Аннан нинди президент чыксын инде? Әнә, ун ел буе «Дом-2»ны төзеп бетерә алмый, ә ил белән ул ни эшли алыр?**



Сергей ЕРМИЛОВ



Иң мөһиме эш түгел, ә документларның йөрүе...

Без монда кул белән түгел, ә бөтенләй башка әйберләр белән эшлибез...

Нормативлар буенча, җир ярты метрга гынаката...

Эшлиләрме алар, юкмы – монысы әһәмиятле түгел... Иң мөһиме: килешену төзү...

Мәсьәләне хәл итү хәл ителәчәк...

Безгә белгечләр кирәкми – безгә башкаручылар кирәк...

Эш башкаручылар белән ешрак очрашырга кирәк: аларда бөтенесе дә тәртиптә диган тойгы барлыкка килергә тиеш...

Без авызны гына ачып утырырга тиеш түгел...

Коллективта дисциплина һәм тәртип бозулар төшә...

«А» дан «Б» га кадәр барысын да белергә кирәк...

(нәчәлник фикерләрен Алиш БАДЫЙКОВ җиткерде)

Ринат АБЗАЛОВ

ЗАКОН БЕР УЛ

Әгәр дә син, гади кеше, ялгыш
Узып китсәң кибет кассасын,
Тәрәзәңне ваткач, колагыннан
Тотып борсаң кеше баласын,
Түтәлеңне пыр туздырган өчен
Бәреп ексаң күрше тавыгын,
Ял көнендә күлдә, нормадан тыш,
Тота калсаң чөгә балыгын,
Исеңдә тот: безнең гадел закон
Аермыйча кече-олысын,
Илле мең сум сиңа ыштраф чәпер,
Ә кирәксә – төрмә срогын.

Әгәр сиңа, олы нәчәлникка,
Ришвәт салса кемдер кесәңә,
Закон бер ул – каты булыр җәза:
Озатырлар, зурлап, пинсәгә...



Игорь КИЙКО

Музей тарихлары

Ни дисәң дә, Казан кебек тарих һәм культурага бай шәһәрдә яшәү күңелле дә инде! Ял көне иртән торасың да хатыныңа:

– Кадерлем, бәлки, бу шимбәдә сәнгать музеена бармый калырбыз? – дисең.

Ә ул җавап бирә:

– Әйдә, бу юлы Милли музейга бармый калыйк әле, сәнгать музеена теге атнада гына бармый калдык ич!

Бу шаярту, әлбәттә. Казанлылар һәм калабыз кунакларының күбесе данлы тарихыбыз белән кызыксына, гүзәллек дөньясына чумарга омтыла, һәм шуңа күрә музейларга рәхәтләнеп йөри. Хәер, музей пулатларында йөрергә яратучыларны кайчагында бу гына кызыксындырмый. Мәсәлән, башка "пулат" — Хисап палатасы хезмәткәрләре игътибарларын бүгенге көн вакыйгаларына юнәлткәннәр. Ачыграк әйтсәк, аларны кайбер культура учакларының бюджет акчаларын кая юнәлтүләре кызыксындырган. Тикшерүләр вакытында 47,4 миллионга бәяләнгән күп кенә кызыклы фактлар ачыкланган.

Ике ел элек Татарстан Милли музее, заманадан артта калмау максаты белән, проектор, монитор һәм акустик системадан торган мультимедиа җиһазлары сатып алган. Ә Л. Н. Толстой музее өчен – классикның үлемсез романын язуының Казан чорына җан өрергә – 200 меңлек антиквар савыт-саба кайтартылган. Ләкин, нигәдер, бу әйберләр күргәзмә залларына һәм экспозицияләргә барып җитмәгән. Сатып алынган кыйммәтле әйберләр склад киштәләрендә тузан җыеп яткан – әллә замана техникасы һәм затлы борынгы савыт-сабага урын табылмаган, әллә музей подвалларында алар яхшырак сакланыр дип уйлаганнар.

Казанның сынлы сәнгать музеенда да шулай ук фикер йөрткәннәр, күрәсең. Анда миллион сумга сатып алынган басма продукция кулланышсыз аунап яткан. Ә "Ленино-Кокушкино" музей-тыюлыгында исә 480 мең сумлык җылыту җиһазларына урын таба алмаганнар. Көтелмәгән нәрсә булган – кайчандыр укуын тәмамламыйча калган студент Ульяновның бабасы яшәгән утарга газ керткәннәр һәм электр приборлары кирәксез калган.

Дәүләт тикшерүчеләре Иске Казан музей-тыюлыгын да читтә калдырмаганнар. Монда вакыйгалар башкачарак юнәлештә барган. Аның мәйданында тарихи-мәдәни һәнәрчелек комплексы урнашкан: сакчы манаралары, агач крепость диварлары, чүлмәкчелек остаханәсе һәм туристларга күрсәтердәй башка нәрсәләр. Шунысы гаҗәп: бу корылмалар бернинди дә бухгалтер документларында күрсәтелмәгән. Чынлыкта, алар бар, ә кәгазьдә юк! Музей җитәкчелеге моны болай аңлаткан: имеш, комплекс 2011 елда ук шәхси хәйрия акциясе буларак төзелгән булган, шуңа күрә музейның бернинди документлары да юк. Югыйсә хәзерге законнар буенча хәтта һәрбер кечкенә бүләк теркәлеп барырга тиеш.


Барлыкка килгән традиция буенча, дәүләт сатып алулары өлкәсендә дә закон бозу очраклары ачыкланган. Монда сумма 10 миллион сум тәшкил иткән. Кечкенә генә мисал. Республика Милли музее һәм "Иҗат" остаханәсе Горький музее бинасында экспозиция ясау турында килешенгәннәр. Казына башлагач, аның өчен алынган материаллар да башка булып чыккан, әзер экспозициядә кайбер өлешләрнең дә җитмәве ачыкланган...

Татарстанның Хисап палатасы белдергән мәгълүматлар яңа тарихи процесска юл салды. Ул тарихны өйрәнү белән хәзер прокуратура шөгыльләнә.


Тимур ШАТОВ




Вячеслав ШИЛОВ



Валерий ТАРАСЕНКО


Илдар НӘФИЕВ


Виктор БОГОРАД



• • •

Бик тә затлы җиһазландырылган фатирга карак керә һәм өстәлдә язу күрә: "Акча эзләп маташмагыз, барлык әйберләр дә кредитка алынган – менә килешүләрнең күчермәсе".

• • •

Аз керемле гаиләләрдән булган студентларга ярдәм программасы эшли башлады. Гыйнвардан башлап мөгаллимнәргә ришвәтне алар 30 процентка кимрәк бирәчәкләр.

• • •

– Әгәр дә үткәнгә кайтырга мөмкинчелек булса, нәрсәне алыштырыр идегез?

– Долларларны!

• • •

– Бабай өйләнергә булды әле.

– Ничә яшь соң аңа?

– Туксан өч.

– Ә кәләшенә күпме?

– Сиксән өч.

– Аны мондый яшь аермасы куркытмыймы?

• • •

Әгәр әз урласаң – озакка утырталар. Әгәр күп урласаң – шартлы рәвештә котылырсың. Әгәр дә инде чамасыз күләмдә урласаң, башкаларны үзең утырта башлыйсың!

• • •

"Әллә инде анда бал белән сылаганнар" дигән әйтемне "Әйтерсең лә анда Wi-Fi бар" дигәне белән алмаштырырга вакыт.

• • •

Ике сердәш сөйләшә:

– Син нигә үзеңнең иреңә "галим песи" дисең? Ул чыннан да шундый акыллымы әллә?

– Чөнки ул һәрвакыт кырыйга йөргәли, ә аннан әкият сөйли.

• • •


– Сезнең компаниягезнең тендерын ота алмам дип куркам.

– Әйдә, 15% ка бәхәсләшәбез – отачаксың?

АКЛЫ-КАРАЛЫ ДӨНЬЯ



Виктор БОГОРАД



Виктор ФЁДОРОВ

Михаил ЛАРИЧЕВ





Илдар НӘФИЕВ



Дамир МОРТАЗИН

БАР ӘЛЕ МОНДЫЙЛАР!..

Куянов сикереп торды. Аның йөзе үзенең хаклыгына ышану хисе белән яна иде. Күзләрендә очкын, ник бер курку әсәре булсын. Бөтен кыяфәтендә – көрәшкә әзерлек.

– Мин сезгә, Гали Вәлиевич, күптән әйтергә теләгән идем, – дип башлады ул кискен рәвештә, – сез бернәрсәгә ярамый торган, булдыксыз җитәкче! Надан һәм тәкәббер, үзегезнең хезмәткәрләрегезне санга сукмый торган бәндә. Сез үзегезне туганнарыгыз, якташларыгыз, ялагай һәм куштаннар белән чорнап алгансыз. Акыллы, белемле кешеләрне яратмыйсыз, аларны коллективтан, хәлләренә кермичә, куып чыгарасыз. Сез оешмабызны үзегезнең шәхси мәнфәгатьләрегезне канәгатьләндерүгә җайладыгыз. Әйе, ул сезнең туган авылыгызның филиалына әйләнде. Әйе, әйе!.. Бөтен халык шулай ди, ләкин сезнең йөзегезгә бәреп әйтергә кыймый. Сез уйлыйсыз, бу эшләрегезне, ягъни ма-хи-нацияләрегезне – акчалар белән чыштыр-пыштыр итүләрегезне диюем, откат ясауларыгызны, штат расписаниесендәге үле җаннар белән әш-вәш китерүләрегезне, өченче коттеджыгызны һәм бишенче иномаркагызны белмиләр дисезме? Беләләр! Һәм төгәл әйтә алам, тиздән бу кыланмышларыгызга чик куелачак! Өстәге сезнең әшнәләрегезгә хана булачак!.. Белеп торыгыз, мин сезне күрә алмыйм! Сез ахмак мактанчык һәм үзеннән бик канәгать тавис!

Куянов тынды.Күңелендә кайнаган ачуын ул әйтеп бетерде. Галстугын бушатты, сулышын җайлап, соңгы тапкыр көзгегә карады да эшенә китте...

Валентин ДРУЖИНИН





БӨТЕНЕСЕ ДӘ УКУ ӨЧЕН

Укыту эшен тиешле дәрәҗәдә алып барыр өчен кайчагында мәктәпләргә әллә нинди көтелмәгән нәрсәләр кирәк булып куя. Татарстан мәктәпләренең берсендә ата-аналарга уналтышар килограмм бәрәңге алып килергә кушканнар, ә “икенче икмәк” булмаган очракта аны акчалата кабул иткәннәр. Ростов-Дон шәһәрендә җитәкчелек кредитка... ишек янына куяр өчен 475 мең сумлык турникет алырга ниятләгән, ә бурычны түләргә ата-аналарны мәҗбүр иткән. Ә Байкал арты өлкәләренең берсендә укучыларга бөтен дәреслекләрне бушлай биргәннәр, тик... аренда өчен акча түләткәннәр: искеләре өчен аена – биш, ә яңаралары өчен – ун сум.

ЕЛЫЙ-ЕЛЫЙ ТАЛАУ

Алабугада битләренә маска кигән ике билгесез бәндә ритуаль хезмәт салонына бәреп кергәннәр. Күздән яшь чыгаручы газ сиптереп, салонда эшләүче кыздан акча таләп иткәннәр. Тик һөҗүм итүчеләрнең үзләренең хәлләре мөшкелләнгән. Талаучылар, берни дә алырга өлгермичә, күзләрен уа-уа салоннан атылып чыкканнар. Хәзер аларны полиция эзли.

ПОЧТА БАШБАШТАКЛЫГЫ

Апас районының почта эшкәртү һәм өләшү цехы башлыгы үзенең карамагындагы оешмада чын башбаштаклык оештырган. Бу ханым өч елга якын торак-коммуналь түләүләре, акча күчерү, посылка һәм газет-журналларга язылу документларына ялган мәгълүматлар кертү белән шөгыльләнгән. Шулай итеп җыелган 613 мең сум “табыш”ны үз кесәсенә салган. Озак вакыт буе тотылмыйча йөрү аның башын әйләндереп җибәргән, күрәсең. Чамасын югалткан ханым почтальонның пенсия өләшәсе акчалары салынган сумкасын алган. Бер миллион сум үзләштереп, ул суд эскәмиясенә барып эләккән.

КЫСЛА “ЭШЕ”

Актаныш районы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрен законсыз кысла “тотуда” гаеплиләр. Елгаларның берсендә, тикшерү белән йөргән чакта, ул кысла тотучы браконьерны тоткарлап, аның белән ике якка да файдалы килешенү төзегән: хокук сакчысы аның законсыз эшчәнлегенә күз йома, ә тегесе полицейскийның өстәлен елга деликатесы белән тәэмин итеп тора. Шулай итеп, бер ел эчендә браконьердан 45 мең сумлык 45 килограмм кысла ите алган. Компаньоннарга каршы җинаять эше кузгатылган.


КОМПЬЮТЕР МОҢНАРЫ


Игорь КИЙКО



Валерий ТАРАСЕНКО

Валентин ДУБИНИН




Игорь КИЙКО



• • •

– Өч программист бизнес оештыра аламы?
– Әйе. Берсе вируслар, икенчесе антивируслар яза.
– Ә өченчесе?
– Шуларны эшләтә торган программалар әзерли!

Михаил ЛАРИЧЕВ



Антон МАКУНИ

Йокысызлыктан дару

Йокычиревкә эштә бик каты эләкте. Эләкмәслек тә түгел шул, чөнки ул начальнигы каршында, утырган килеш, түнәнитә йокымсырап китә иде. Ә менә төнлә, рәхәтләнеп йокларга дигәндә, килми дә килми шул нәмәрсә.

Әйләнгәләп-боргаланып сәгать ярым яткач, Йокычирев ничек йокыга талу турында уйлана башлады. Һәм шул вакыт башында бер акыллы фикер туды: "Нинди дә булса яхшы, яраткан нәрсә турында уйларга!"

Йокычиревнең иң яраткан уе футбол иде. Шуңа күрә ул, күзләрен йомып, футбол кырында уйнаучы "Рубин" командасын күзаллады. "Ә көндәшләре итеп... – диде ул, бер секундка тын калып, – әйтик... Манчестер Юнайтед булсын!" Куанычыннан хәтта кулларын уып куйды. "Хәзер "Рубин" аларны чәчтереп ыргыта! Йокычиревнең йөзендә канәгатьле елмаю барлыкка килде, әнә Бердыев житди кыяфәттә тәсбих төймәләрен тарта, стадион шаулый, "Рубин" һөҗүм итә, пас, удар! Туп капка өстеннән очып үтә..."

Йокычирев күзләрен ачып, маңгаендагы тирен сөртә. "Ничек шулай булды соң әле бу?! Әй, мин бит моны күз алдыма гына китерәм! Менә хәзер икенче төрлерәк булыр, "Рубин" инглизләргә унны... юк, унбиш тупны кертәчәк!" Йокычирев күзләрен яңадан йомды... "Менә "Рубин" тагын алга ыргылды, флангтан туп уртага очты, удар! Инглизләрнең капкачысы уйнап кына тупны тота һәм... нәрсә бу?!. Кырның буеннан-буена тупны тибә, ә аны анда Златан Ибраһимович эләктереп ала да, безнең сакчыларны җайлы гына алдап, бар көченә капкага таба тибә! Гол!"

Йокычирев караватыннан сикереп тора: "Ничек гол? Кемгә?! "Рубинга"?!

Алга таба нәрсә булып беткәнен Йокычирев карап бетермәде, бүлмәсе буйлап, аңга килә алмыйча, йөренергә тотынды...

Шуннан соң, ике сәгатьләп вакыт үткәч кенә ул кабат йокларга ятарга булды. "Менә тагын иртәгә эштә миңа кирәкне бирәчәкләр!" – дип уйлады Йокычирев. – Килермен, күренермен, йокламаган, юынмаган... Йә Алла, нәрсә килеп чыгар инде?!"

Ачудан бүртенгән начальнигының чыраен күз алдына китерде. Ә ул һаман, җүләр сыман, аның каршында утырган килеш йоклар... Шулчак Йокычирев тәмле итеп иснәде дә каты йокыга талды...

Иртән ул күтәренке кәеф белән уянып китте һәм шатланып эшенә атлады. Шул көннән алып, эшендә аның бернинди чатаклыклар барлыкка килмәде. Әгәр дә йокысы килсә, беләсез инде, нәрсәне һәм кемне күзаллаганын...

Хәтәр – башыңа җитәр!



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Ринат АБЗАЛОВ

АЕК ФИКЕРЛӘР

Беләсезме: кальцийда бер көнлек мохтаҗлыгын каплар өчен кешегә бары тик 26 литр сыра җитә.

Хәмер җавап табарга ярдәм итми, ул мәсьәләне онытырга булыша.

Эчүнең өч сәбәбе бар: бөтенесе дә шәп, барысы да начар, үзеңне кая куярга белмәү.

Бер шешә эчкәннән соң, аңгәмә мәгълүмат бүлешүгә әйләнә.

Бездә генә, туганнар, дуслар һәм иптәшләрдән башка, «бергә салган идек» дигән танышлар бар.

Тормышында нәрсә эшләргә белмәгән кеше, ике стакан аракыдан соң, ил белән нәрсә эшләргә икәнен белә.







Нажия БӘХТИЕВА

Кешенеке, үзеннеке


Нигә шулай була икән? Бәйрәмнәрдә әгәр артыгын җибәрсә, үземнекенә карый алмыйм. Чын дуңгыз инде! Ә башкалар, күбрәк эчсә дә, шундый мөлаем, матур!

Күрше хатыны иремнең куллары алтын ди, ә үзенекен кыек кул дип атый, имеш, аннан соң бөтен нәрсәне өр-яңадан эшләргә кирәк. Үзем дә шулай – ул алтын кулны үгетләгәнче, үзең эшләү хәерлерәк. Кызым кияүгә чыгарга ашыкмый – җүнле егетләр юк. Ә күрше кызы һаман ир таба алмыйча интегә: сайланган була… Ә балалар? Оныкларыма сокланып туя алмыйм, шундый матур алар! Ә күршеләрнекенең шуклыкларына чыдый алмыйм!

Кияүдәге кызым эшчән – бал кортымыни. Кияү – ата ялкау, балыкка йөрүдән башка берни белми. Ә улымның хатыны булдыксыз: аңа киенеп-ясанырга гына булсын, улымны балыкка барып кайткан өчен ашарга әзер.

Бәрәңгебез ярмалы, авызда эреп китә. Күршеләрнеке, уңышы күп булса да, сабын кебек, авызга алырлык түгел. Кыярлары да зур, калын, хуш исле түгел. Нишләп кеше казы күркә булып күренә икән? Нәрсәгә генә тотынма – чагыштыра башлыйсың. Ничек котылырга икән бу гадәттән?

Михаил ЛАРИЧЕВ





Александр СЕРГЕЕВ

Вячеслав БИБИШЕВ



Илдус АЗИМОВ



Ринат БӘШИРОВ





• • •

Табигать белеме дәресендә укытучы сорый:

– Кем белә, ни өчен ләкләкләр кышка Африкага очалар?

Әхмәт:

– Билгеле инде, алар анда да балалы булырга телиләр!

• • •

Тормышның үзгәрүен карале син! Хәзер минем мәчем куян итеннән рагу ашый, ә мин – соялы пилмән.

• • •

– Ни өчен ришвәтчелек белән көрәш алып бару файдасыз?

– Чөнки барысы да ришвәтчеләргә нәфрәт белән карый, ләкин һәрберсенең шулар кебек буласы килә.

• • •

– Нигә эчәсең?

– Бу бит корпоратив.

– Ә нигә берүзең?

– Мин шәхси эшкуар.

• • •

– Әбекәй, сәламәтлегегезне тикшердем, сез сәламәт. Аңлатыгыз әле тагын бер мәртәбә: кайсы җирегезгә зарланасыз?

– Сулышым кыса.

– Кайчан?

– Автобусны куып тота алмасам.

• • •

Партия төзү мәсьәләсенә кагылган сорау.

– Хәзерге вакытта сез нәрсә белән мәшгуль?

– Яңа типтагы партия төзибез.

– Нинди стадиядә инде ул?

– Менә шул типны эзлибез инде.

• • •

Сәер дә инде бу ир-ат халкы... Кичә миңа берәү әйтә: "Хәлемнән килсә, өйләнер идем", – ди. Кара син аны... Хәле юк, ә өйләнергә тели...

• • •

Телевизордан куышулар, катастрофалар, кризислар күрмисез икән, димәк, сез реклама карыйсыз.

КИЛЕП ЧЫКМАДЫ

2008 елдан соң Алмаз Хәмзин фаразлавы.

Җәмәгать, ни өчен Казанда галәмәт зур ике "М" хәрефе төзеп куйдылар? Берсе Оренбург ягыннан кергәндә тора, икенчесе – күпер өстендә. Юк-юк, Казанны сез ирләр бәдрәфе дип уйламагыз! Ул аның өчен куелмаган. Сөбханалла, шәһәребез чиста. Шәһәр башлыгыбыз бик уңган, булган кеше. Миллионлы шәһәр булганга, дисезме? Алай дисәң, Мәскәү гел "М" хәрефе белән тулган булыр иде. Мин дә белмим шул. Путин да белми икән. Сорый, ди, бу бервакыт Минтимер Шәриповичтан:

– Что за буква "М" у Вас, Минтимер Шарипович на мосту? Минтимер что-ли?..

– Нет, это не за это...

– Мухаметшин что ли?

– Нет, и не из-за этого...

– Минниханов, что ли?

– Опять не попал...

– Метшин что ли?

– Не отгадаешь, Владимир Владимирович.

– Ну скажи, очень интересно узнать!

– Это место моста, – дип әйткән, ди, имеш безнең Президент, елмаеп.

Үзегез күреп, белеп торасыз, хөрмәтле журналны укучыларыбыз, Татарстан икътисады көчле, халыкның яшәү дәрте дә зарланырлык түгел, Аллага шөкер. Республикабыз горли. Шуңа күрәдер "Үзәк" үзенә бу юлы бездәге кебек "М" хәрефенә башланган фамилияле Президент сайлап куйды. Бирсен Ходай, бәлки тормышларыбыз тагын да ныграк әйбәтләнеп китәр.


Анысы шулай, ләкин бит әле "ин" хәрефләренә бүтән фамилияле шәхесләрне дә даһилар дип уйлыйм мин. Әйтик, Ленин, Сталин, Путин... Хәмзин.

Урыс әйтмешли: "Черт чем не шутит?! Аның бит тарихи закончалыгы да бар әле. Президентлар, генсеклар булуның, мин әйтәм. Менә Ленин пеләш булган, аннан соң Сталин – чәчле (мин озак вакыт хаким иткәннәрне санап китәм), Сталиннан соң Хрущев – пеләш, Брежнев – чәчле, Горбачев – пеләш, Ельцинның чәче бар, Путинныкы тагы юк, инде Медведевныкын үзегез күреп торасыз – куе. Медведевтан соң кем булыр? Сезне сәламләп торучы абзагызга күз салыгыз. Урысчага күчәм: "Так что готовьтесь, господа!"

...Бөздылар чиратны...







Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 21, 1986

– Ике браконьер тотар өчен лицензиябез!



Юрий ДЕНИСОВ, «Чаян» № 7, 1991

– Исеңдә тот, Кащей, мафия генә үлемсез була ала!





Таһир ФӘИЗОВ, «Чаян» № 4, 1988

– Минем урынга каласың – Сингапурга тәҗрибә уртаклашырга китәм!

Мәхмүт ХӨСӘЕН

ЯРАП БУЛМЫЙ ХАТЫНГА

Тәмәкене тартмадым,
Эчә идем – ташладым;
Эшемнән дә вакытында
Өйгә кайта башладым.
Һай, шулай да эш харап:
Хатынга булмый ярап.

Уртанчысын уйнатам,
Иң кечесен йоклатам.
Чебен тими чер иткәнен
Елавыннан туктатам.
Һай, барыбер эш харап:
Хатынга булмый ярап.

Суын булса – китерәм,
Керен булса – киптерәм;
Идәнен булса – себерел,
Көзгедәй ялт иттерәм.
Һай, болай да эш харап:
Хатынга булмый ярап.

Тозлыйм кыяр, каклыйм каз...
Ял итим дисәм бераз:
"Син – ир кеше, сиңа – ди ул, –
Җитмеш төрле һөнәр аз!"
Уф, арыдым... эш харап:
Ничек тә булмый ярап!..



Виталий ФЕОКТИСТОВ, «Чаян» № 11, 1982

– Ыштаныгызның бөтен якка тигезлеген нәрсә белән исбатларсыз, Пифагор?

Әмир ДАУТОВ

ГАЕП ТАНУ

– Без сезне кулга алабыз! Гаебегезне танырга туры киләчәк!

– Нәрсәне танырга?

– Сез өч профессиональ боксерны кыйнагансыз!

– Мин үземне саклау өчен генә! Алар үзләре башладылар бит...

– Карале! Бу шау-шулы эш – боксерларны көн саен кыйнамыйлар. Моны өстәге Үзе контрольдә тота... Сиңа үз гаебеңне тану әйбәтрәк булыр, ә суд моны исәптә тотар...

– Минем бер көтү шаһитларым бар... Алардан көчкә качып котылдым!

– Ә бездән кача алмассың! Аларның берсенең әнисе – депутат, икенчесенең абыйсы "Газпромнан", ә өченчесе – өлкә дәрәҗәсендәге авторитетның улы.

– Сезнең намусыгыз бармы?!

– Минем закон нигезендә сине җәмгыятьтән читләштерергә хакым бар!

– Боксерлар җәмгыятеннән?

– Йә, ярар! Боксерларны кыйнауны алырга теләмисең икән, алайса ларекларны талауны үз өстеңә ал һәм вәссәлам! Бер өч елдан күрешербез...

– Бәлки, миңа урамны тиешле урында чыкмаган өчен штраф түләү яхшырактыр? Ике штраф! Өч!


– Сай йөзәсең... Ләкин мин сиңа тагын бер вариант тәкъдим итеп карыйм... Педофил итеп!..

– Нәрсә-ә-ә?! Чукынып китегез! Боксерларның өчесен дә мин кыйнадым! Әйе!

– Күптән шулай диләр аны! Үз ихтыярың белән гаебеңне тануыңны яз – бәлки, суд кәләр-кәләр дә, биш кенә елга хөкем итәр. Шартлы рәвештә... Яз... яз... Ә мин хәзер шалтыратам да җәмгыятьне шаулаткан җинаятьне ачу турында отчет бирәм...



Вячеслав ШИЛОВ



Максим СМАГИН



Александр КОСМЫЛИН

ТУГАН АВЫЛ ТУРЫНДА

Туган авыл...
Мең кат таныш җырлар:
Куе урман, яшел тугайлар,
Иркен басу-кырлар, саф чишмәләр,
Күкләрендә сайрый тургайлар...
Хуш иследер аның болыннары,
Бормалыдыр аның сулары,
Шаулап үсә анда мул игеннәр,
Эшчән аның кыз һәм уллары...

Табармын дип яңа бер җылы сүз,
Тыңлап карыйм тагын, тагын да.
Уйлап куям: тудык микән әллә
Бөтенебез бер үк авылда?

Ишетергә иде җанны ярып
Кергән сүзне,
күңел сусагач.
...Җырлар язмыйк, дуслар, "авыл" диеп,
Үзәк өзгеч сүзләр булмагач...

Ринат АБЗАЛОВ



АЛГА БАРЫРГА КУШКАН БИТ БЕЗГӘ ЛЕНИН БАБАБЫЗ...

РЕВОЛЮЦИЯ ТУРЫНДА ГЫЙБАРӘЛӘР

Революцияне романтиклар уйлап чыгара, фанатиклар тормышка ашыра, ә аның җимешләреннән кабахәтләр файдалана. **(Отто фон Бисмарк)**

Революцияләр беркайчан да авырлыкларны җиңеләйтми, аларны башка җилкәгә генә күчерә. **(Бернард Шоу)**

Революцияләр революционерларны юк итү өчен кирәк. **(Максим Горький)**

Революцияләр шахмат уенына охшаган – пешкалар корольне саклап калырга да, аның урынын алырга да мөмкиннәр. **(Пьер Буаст)**

Революцияләр бер якның укымышлылыгыннан түгел, ә икенче якның ахмаклыгыннан килеп чыга. **(Антуан де Ривароль)**

Революцияне акыллы кешеләр әзерли, ә бандитлар башкара. **(Мариано Асуэла)**

Революция – штык белән коралланган идея. **(Виктор Гюго)**

Вакыты-вакыты белән ярлылар бергә җыелып, байның милкен талап, үзләре баю өчен бер-берсе белән сугыша башлыйлар. **(Вильгельм Швебель)**

Революция вакытында беркайчан да демократия булмый. **(Николай Бердяев)**

Әгәр илдә хезмәт хакы тоткарлана башласа, ул ил революция белән авырлы дигән сүз. **(Герман Дробиз)**

Революцияне башлаучылар, гадәттә, аны тәмамлаучылар түгел. **(Роберт Грин)**

Интеллектуаллар ач калса, алар бәрәңге утырту турында түгел, ә революция оештыру турында уйлаячаклар. **(Вильгельм Швебель)**

Фәкыйрьлек – революциягә, ә революция фәкыйрьлеккә этәрә. **(Виктор Гюго)**

Нияз БИШБАЛТА туланмасыннан

КАЗАН.





Валерий ТАРАСЕНКО



Байлар, пайлар һәм югалган акчалар турында

Берзаман бер Америка фермерыннан: "Нигә сез җитештергән продуктларның бәяләре күтәрелә?" – дип сораганнар. Ул җавап биргән: "Чөнки хәзер миңа үстергән культураларымның фәнни исемнәрен белергә, зоология китаплары буенча аларны ашаучы корткычларны һәм аларга каршы көрәшү чараларын өйрәнергә кирәк. Моның өчен кемдер түләргә тиеш бит!" Бу гыйбарәне ишеткәч, безнең фермер, моңсу елмаеп: "Эше булмаган эш тапкан..." – дип тирән сулап кына куяр. Һәм тулысынча хаклы булыр! Иртәдән кичкә кадәр адым саен: "Кече бизнеска – киң юл!" – дип кычкыруга карамастан, ул юлда куелган киртәләр артканнан-арта бара. Элекке колхозлар милкенә хуҗа булып киткән бай "латифундистлар"ның кече агробизнес вәкилләрен һәрьяклап кысалар...

Узган ел Чүпрәле районының Кече Цильна авылы фермеры Айрат Хәмдиев авылдашларының җир пайлары бәрабәренә сөрү мәйданнарын арттырырга булган. Һәм аларга яхшы гына дивидендлар тәкъдим иткән – һәр гектар өчен бер центнер икмәк. Бу өметле вәгъдә пайчыларда зур кызыксыну уяткан. Элек алар пайларын «Цильна» җәмгыяте агрохолдингына арендага биреп, андагы арендатор әфәнделәрдән бер центнер икмәкне дүрт гектар өчен генә ала торган булганнар. Ә монда агрохолдинг белән аренда срогы да чыккан. Нигә фермер белән күпкә отышлырак шартларда яңа килешенү төземәскә? Нәтиҗәдә, "Цильна" канаты астыннан 54 гектар җирләре белән 13 кеше Хәмдиевкә киткән. Бераздан тагын 13 пайчы аның белән аренда килешенүе төзергә карар кылган. Фермер, дәртләнеп, яз көне үк яңа җирләрдә сөрү-чәчү эшләре башларга җыенган: орлыклар, ягулык, техника сатып алган... Тик тормыш син дигәнчә генә бармый шул!" Цильна" җәмгыяте җитәкчесе Барис Гыйрфанов фермерны... ялган имзалар белән эш итүдә гаепләгән. Хәмдиев район судында бөтен документларның да чиста булуын исбатлап йөргән арада, пайчыларның бер өлеше килешенүләреннән баш тартырга өлгергән. Фермер фикеренчә, бу "Цильна" җитәкчелеге басымы астында эшләнгән. Республика Иҗтимагый палатасы юристларының Хәмдиевнең эшчәнлегендә бернинди кыек яклар тапмауга карамастан, район хөкемдарлары фермерга яңа җирләрдә сөрергә дә, чәчәргә дә тыючы карар чыгарганнар. Кыскасы, кем бай, шуңа – пай. Хәмдиев, әлбәттә, югары суд инстанцияләренә барып җитәргә әзер, тик хәзергә күргән матди зыянын исәпләү белән шөгыльләнергә мәҗбүр.

Нурлат фермеры Марсель Сабиров исә, гомумән, "крепостной крәстиян" хәлендә калган. Ул инде берничә ел үзе җитештергән сөт тапшыру белән шөгыльләнә. Ләкин Аксубай районы һәм Ульяновск өлкәсенә җибәрелгән продукциясе өчен акчаны ул айлар, хәтта еллар буе ала алмый. Ульяновск өлкәсе са-



тып алучыларының гына аның алдында ике миллион ярым бурычы бар. Арбитраж суды бурычны кайтарырга мәҗбүр итүче карар чыгаруга карамастан, Сабировның, инде ел ярым үтеп тә, ул акчаларны күргәне юк. Алар өлкәнең куе урманнары эчендә адашып калганнар, күрәсең. Һәм компетентлы органнар катнашыннан башка табуы кыен булыр...

Алексеевский районы Зур Тиган авылы фермеры Илнар Яруллин да туган авылында үзен хуҗа итеп тоя алмый. Бер ел элек ул сөт фермасы өчен банкротлыкка төшкән "Вамин" империясенең ике буш калган складын сатып алырга булган. Тик банкрот милегенә Мари Илендәге "Звениговский" кооперативы башлыгы И. Казанковның күзе төшкән. Күршедәге Кыркүл авылында ул зур агрокомплекс төзергә булган. Һәм Зур Тигандагы складларны сүтеп, төзелешенә андагы бетон плиталарны кайтара башлаган. Мондый башбаштаклыкка фермерның ачуы чыгып, ул сүтелмичә калган соңгы складны сакларга баскан. Яруллинга законсыз гамәлне туктатыр өчен дүрт тапкыр полиция чакыртырга туры килгән. Үзе исә күп тапкырлар складларны сатып алу үтенече белән конкурс идарәчесенә мөрәҗәгать иткән. Хәзерге вакытта бөтен банкрот милегенең берьюлы аукционнан сатылачагы билгеле. Ул, әлбәттә, кемнең акчасы күбрәк, шуның кулына эләгәчәк. Моның кем булачагы турында баш ватуның да кирәге юк. Үзен "дөнья хуҗасы" итеп тойган байгураның ниндидер фермер кисәгенең теләгенә нишләп киртә була алсын, ди...

Ярый, хәзер бөтен нәрсәне дә акча хәл итә икән, шулай булсын. Ләкин менә шуннан соң, бөтен югары трибуналардан сөйләнгәнчә, фермерлардан зур савымнар һәм мул уңышлар көтәргә туры килер микән?

Айдар СУБАЕВ


Валентин ДРУЖИНИН

Ринат МИРЗАЯНОВ




Александр СЕРГЕЕВ







Уманда күптәннән беркемнең дә күренгәне юк иде!




?







Александр АЛЁШИН

КРЕАТИВ ЭСКӘМИЯ

Кадерле Чаян! Төрле ил шәһәрләрендә матур дизайн ысуллары кулланып ясалган заманча эскәмияләр күрергә була. Үзләренә җәлеп итеп, алар яраткан ял итү урыны булып торалар. Шундый эскәмия Казан шәһәрендә дә бар. Габишев һәм Кол Гали урамы кисешендәге автобус тукталышында әлеге экземпляр куелган. Ул утыргычның асылы шунда – артык биек ясалуында. Урта буйлы кешенең җилкә чамасындагы якынча биеклектә ул. Эскәмиягә утыру бәхете һәркемгә дә тәтеми. Әлеге креатив эскәмия дә шәһәрнең үзенчәлекле урынына әйләнеп, әһәмиятле урын яулап алыр дип ышанасы килә. Шуңа күрә кешеләр аның янында басып торырга да риза.

Л. НИКОЛАЕВА

КАЗАН



ӨЙДЕЛӘР ДӘ КАЧТЫЛАР

Хөрмәтле Чаян! Йортыбызның "әсирлеккә" алынганына ярты ай инде. Подъезд юлларын төзекләндерү эшләре сентябрь аенда башланып киткән иде. Асфальтны салдырып, берничә машина вак таш сибү белән эшләре кинәт тукталып калды. Эшчеләр юкка чыкты, подъездга керү юлын томалаган вак таш өеме шул килеш кала бирә. Йортларыбызга хәзер ашыгыч ярдәм, ут сүндерү машиналары үтеп керә торган түгел. Ә безгә исә үкчәләрне вата-җимерә, аякларны бәрә-суга, шуннан йөрергә генә кала...

Энгельс урамы, 89 нчы йортта яшәүчеләр

ЧИСТАЙ





САКЛАНУ МӘЙДАНЫ

Чаян дус! Безнең "Октябрьгә – 70 ел!" бакчачылык оешмасына 30 ел. Шул дәвердә безгә карата бернинди дәдәгъва булмады. Тыныч кына йортлар салынды, бакчалар үсеп чыкты, уңыш җыелды... Беркөнне, аяз күктә яшен суккан сыман, Константиновка җитештерү идарәсеннән 200 дән артык бакчачыга шундый кәгазь килеп төште. Анда акка кара белән. "Магистраль" газүткәргеч саклау мәйданына якын төзелгән төзелешләрне сүтәргә" дигән мөрәҗәгать ярылып ята иде. Нигә инде сүтәргә? Җирләрне сатып алганда барыбыз да кануннарга таянып эшләдек ләбаса. Көтмәгәндә сүтеп ат, имеш!

Иң кызыгы: әлеге мөрәҗәгатьтән башка бакчачылык идарәсенә бернинди рәсми кәгазь килмәгән. Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән телефоннар дәшми, ә хуҗаларына бөтенләй якын килә торган түгел, ни дисәң дә, аларның үзләренең саклану зонасы...

З. ИВАНОВА, М. САНИН, Н. КОВАЛЁВ

Барлыгы 50 дән артык имза.

ЯШЕЛ ҮЗӘН

МЕНӘ ШУЛАЙ ЯШӘП ЯТАБЫЗ...

Кадерле редакция! Гадәттә, бистәләрнең үзәк урамнарын гына булса да, бөтен шартларын үтәп эшлиләр. Яхшы юллар ясыйлар, баганаларда утлар яна, җайлы тукталышлар, башка уңайлы шартлар... Ә менә безнең бистәнең үзәк урамы андый бәхеткә ирешә алмады. Юлларны көчкә, аннан-моннан төзекләндерергә булдылар. Халык йөрсенгә тротуарлар да каралмаган. Бөтен бистәгә берләнбер юлны аркылы чыгу – ул да булса мәктәп янында. Җәй көне котырып үскән яшеллек арасыннан җәяүлеләрнең килеп чыкканын абайламый да калырга мөмкин машина йөртүчеләр. Балалар ике смена укыганлыктан, караңгыда аларны күреп бетерергә мөмкин түгел, чөнки урам яктырткыч баганалар еракта урнашкан. Ә автобус тукталышы өчен махсус "кесә" дә каралмаган. Халык автобуслардан машина чаба торган юлга төшәргә мәҗбүр. Менә шулай, бөтен уңай шартлардан мәхрүм булып, үзәк урамда яшәп ятабыз.


Г. ТӨХВӘТУЛЛИНА


САЛМАЧИ
КАЗАН



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ







Евгений ОБУХОВ

АВЫЛ ТАБИБЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Күрше авылга авыру янына чакырдылар. Кыяфәтенә караганда, инсультка охшаган. Нәрсә бирергә? Авыл кибетендә бу очрак өчен чикләвекле «Натс» кына – рекламада әйтелгәнчә, «баш миенә шифа». Нишлисең бит, шуңа рецепт яздым да, күрше авылга киттем.

Анда тагын бер авыру – аягын сындырган. Монда бөтенесе дә аңлашыла: авылда егерме ике кеше, шуңа күрә аптеканы әле япмаганнар, тик аптекаларында «Коррега» гына сатыла. Әгәр инде ул теш протезларын ябыштыра икән, сынган сөякне нигә ябыштырмасын, ди?..

Кичкә таба амбулаториягә бер бабайны китерделәр. Плеврит, бронхит, үпкәсе авырта. Көч-хәл белән сулый үзе. «Жевачка» – резина сагыз бирдем. Реклама алдамас – «аэродулкыннар – иркен сулыш» бит.

Әбәттән соң авыл урамыннан юлны аркылыга-буйга айкап, трактор узган һәм күпердән барып төшкән. Юк, тракторы күпердә калган. Ә менә егет каты гына борынын җимергән. «Тампакс» язып бирдем, канны ике тапкыр күбрәк сеңдерә торганын.

Күпер янында шул трактор астына чак кына мәктәп директоры эләкми калган. Үзе, өстәвенә, китапханә һәм клуб мөдире икән әле. Алай ул-бу булмаган, тик кәефе бик кырылган. «Баунти» – оҗмах ләззәте» язып бирдем.

Кояш баегач, элекке кохоз председателе килеп, сәгать ярым зарланып утырды. Симптомнарын язып алып, белешмәне актарып карадым. Бер авыру туры килде – көшектерүче галакта Персия аменорея. Өенә кайтып бөркәнеп ятарга да реклама карарга тәкъдим иттем. Ярдәм итәргә тиеш дип уйлыйм!

НИШЛӘРГӘ ДӘ БЕЛГӘН ЮК...

Бирергәме?

Әллә бирмәскәме?

Катлаулы мәсьәлә. Бирмәсәң әллә ничек – яхшы кешене кимсеткән кебек була. Ни дисәң дә, инде күпме вакыт минем өчен янып, кайгыртып йөри. Тагын нәрсә эшлим синең өчен, дигән кебек, күзгә карап кына тора. Күзләре зәңгәр, нурлы, матур – нәкъ беренче ирем Мотыйгулланыкы кебек. Кулын биргәч, эреп китәм – шундый йомшак, назлы алар! Тик бирүнең тискәре, катлаулы яклары да җитәрлек шул – соңыннан кеше теленә эләгеп, яманатың чыгуы мөмкин. Ул чагында инде эш белән дә, йорт-гаилә, иреңнең кайнар кочагы белән дә бик озакка хушлашырга туры килмәгәе. Бәлки бөтенләйгәдер дә...

Бәлки бирергәдер?

Вакытын туры китереп, аулаграк урын тапсаң, анысы хатын-кыз өчен катлаулы нәрсә түгел, кәнишне. Моны бит инде безнең күп тапкырлар эшләгән бар – тәҗрибә җитәрлек. Аннары – биргәч, ул инде сиңа нәрсәдер тиеш кебек кала — теләсә кайчан мөрәҗәгать итеп, теләгән нәрсәңне сорарга була. Тагын бер тапкыр биреп, әлбәттә. Ә нәрсә, бөтенесе шулай яши әле, беркемгә дә әллә ни булганы юк. Гомумән, бирү ул – берни белән дә чагыштырып булмый торган ләззәт. Күзне күзгә текәп, җаннарның уртак уйлар аша берләшүе – үзе бер дөнья бит ул. Шул нәни бер дөнья бөтен зур дөньяны бергә бәйләп тота бит әле!..

Шулай да бәлки бирмәскәдер?

Ник дисәң, күңелдәге тойгы-кичерешләр – бер нәрсә, ә бу турыда хәбәрнең өскә китүе, җәмгыять фикере – бөтенләй башка әйбер. Аннан соң, закон дигән нәрсә дә бар бит әле. Бигрәк тә ришвәтчелеккә каршы көрәшне көчәйтү турында указ чыккач, адым саен сагалап кына торалар. Бигрәк тә безнең ише ярлы-ябагайны...

Юк! Бирмим!

Ринат АБЗАЛОВ





Алексей БУЛАТОВ






Валерий ТАРАСЕНКО



Вячеслав ШИЛОВ





• • •

Инглиз телен өйрәнү өчен Англиягә барган идем, килеп чыкмады, төрмәгә утырдым. Ел буе дәүләт асравындагы инглизчә сөйләшүче өйрәнүчеләр арасында булдым. Хәзер менә дигән итеп һиндча һәм гарәпчә сөйләшәм, ә инглизчә – элеккечә, сүзлек белән...

• • •

1 нче сыйныф. Укытучы:

– Ярар, балалар, смартфоннарыгызны-телефоннарыгызны куеп торыгыз әле, җитәр сезгә язышырга. Бүген безгә "А" хәрефен өйрәнергә кирәк.

• • •

– Кадерлем, безнең акчабыз бармы?

– Юк.

– Ничек инде ул алай? Мин бит кичә сиңа бөтен хезмәт хакымны бирдем.

– Минем акчам бар. Безнеке – юк.

• • •

– Син мине өйләнешкәч тә яратырсыңмы?

– Һичшиксез! Кияүдәге хатыннарны бик яратам мин.

• • •

Әнисе баласын йоклатырга җыена һәм аңа бишек җыры җырлый. Бер сәгать җырлый – улы йокламый, ике сәгать – һаман шул ук хәл. Өч сәгатьтән соң баласы әйтә:

– Әни, бәлки, мин йоклармын, ә? Әллә синең һаман җырлыйсың киләме?

• • •

Белдерү: "Хөрмәтле сатып алучылар! Финанс кризисы булу сәбәпле, безнең бутик яңадан кием-салым базарына әйләнеп кайтты".

• • •

– Әни, татуировка ясатырга телим!

– Каешыңны алып кил әле, хәзер әтиең белән суктырып ясыйбыз.





УҢЫШСЫЗ ТӘҖРИБӘ

Бер ай элек Архангельск шәһәрендә яшәүче Артём Шишков башлап җибәргән “Минималь хезмәт хакына яшәп кара” проекты уңышсызлыкка дучар булган. Аена 7800 сумга яшәүнең мөмкин түгеллеген ул бик тиз аңлап алган. Шуңа күрә аз ашаган, ит, балык, җиләк-җимештән баш тарткан, тик ике атнадан акчасы бетеп, барыбер суда пешкән солы боткасына күчәргә туры килгән. Бер ай эчендә Шишков биш килограммга ябыккан һәм сәламәтлегенә зыян китермәс өчен, тәҗрибәне туктатырга мәҗбүр булган.

ЗАКОНСЫЗ ВӘКАЛӘТЛӘР

Орёл өлкәсендә карак депутатны хөкем иткәннәр. Псков районының вәкаләтләр иясе танышының машинасыннан аның банк картасын чәлгән. Счёттан 120 мең сум алып, халык мәнфәгатьләрен яклаучы берничә көн шул акчага кәеф-сафа корган. Бушлай күңел ачучыны суд урланган акчаны кайтарырга мәҗбүр итеп, дәүләт файдасына 150 мең сум кертергә дип карар чыгарган. Халык ышанычыннан колак каккан депутатның мал-мөлкәтен хокук органнары карамагында калдырганнар.

КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК ӨЧЕН

Иркутск өлкәсенең Онгурен авылында көтелмәгән хәл барлыкка килгән. Мәктәп яныннан узган сукмакта җәяүлеләр өчен кичү билгесе урнаштырганнар. Моннан аена уртача 2-3 машина уза, ә кечкенә төбәкнең үзендә барлыгы биш шәхси автомобиль исәпләнә. Ләкин кайгыртучан автоинспекция әһелләре мәктәп булгач, “зебра” да булырга тиеш дип карар кылганнар.

КРЕДИТ АЛУГА КИРТӘЛӘР

«Сбербанк»ның вице-президенты Александр Веденяхин, киләсе елдан иҗтимагый челтәрләрдә банк заёмщикларны аларның уңай билгеләрне нәрсәгә куюлары буенча бәяләү системасы кертеләчәк, дип белдергән. Мисал итеп, Веденяхин «Владимирский централ» дигән төрмә җырын билгеләгән файдаланучыны китергән. Мондый җырлар белән кызыксынучыларга кредит алу кыенрак булырга тиеш, күрәсең.


Игорь КИЙКО



Александр СЕРГЕЕВ



Ринат АБЗАЛОВ



Максим СМАГИН

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Безнең яшәеш белән Конституция түгел, ЖКХлар идарә итә түгелме?

Алмаз Хәмзин: Тегеләре һәм болары бергә идарә итсә дә барыбер безгә булмас күңелле.

Р. Н.: Безгә сайлау нәтиҗәсен сайлаучылар түгел, бюллетень кәгазен санаучылар хәл итә.

А. Х.: Бюллетень санаучыларны өстән сайлап куючылар хәл итә.

Р. Н.: АКШ гарәп илләрен "зомбировать" итәргә җыена, ахрысы...

А. Х.: "Зомбировать" кына түгел, "бомбордировать" итәргә маташа ул.

Р. Н.: Телевизордан күрдеңме, экс-министр Улюкаев тоткынлыкта безнең кебек гади күлмәктән яисә свитердан йөри башлады.

А. Х.: Безнең кебек кенәме соң, хәтта уздыра да... Озакламый, димәк, чыгачак...

Р. Н.: Алмаз туган, синең 70 яшьлек юбилееңнне ничегрәк узып китте? Ул көнне шампан шәраблары пушка кебек атты, диләр...

А. Х.: Ник, син анда юк идеңмени?

Р. Н.: Сине гел "шигъри дуэль"гә чакыра торгач, минем дары мичкәсе шактый бушап калды.

А. Х.: Чын шагыйрьгә,
яшәп мондый илдә,
Бушыймы соң шигырь мичкәсе?!
Синең белән "Чаян" битләрендә
Атышыйкчы "дары" беткәнче!

Р. Н.: Без гел читтә. Президент янәшәсендә фотога төшү өчен Роберт Миңнуллин кебек елгыр егетләр кирәк.

А. Х.: Сөен. Ярый әле президент та, Миңнуллин да булмаганбыз, диген...

Р. Н.: XXI гасыр. Нанотехнология. Без машина һәм планшет-смартфон коллары булып калмабыз микән?

А. Х.: Без инде хәзер кол булырга да ярамыйбыз...

Р. Н.: Казанда "Хан сарае" дигән ресторан ачылды, ә менә татар ханнарына һәйкәл куелганы юк.

А. Х.: Һәйкәл табыш китерми бит ул...

Р. Н.: Шагыйрь – ул халкының адвокаты булырга тиештер.

А. Х.: Чын шагыйрь адвокат була алмый, чөнки аның акчасы да юк, намусы да чиста.

Р. Н.: Буш күңелгә шайтан иялләшә!

А. Х.: Юмарт күңелгә – барысы да шат, әйеме, Рашат?!

ПЕТЕБУРГТА КАЗАН МӘЧЕЛӘРЕ

Казанда, һәйкәлләрнең күз иялэнеп беткәннәреннән башка, гадәти булмаганнары да байтак. Берничә ел элек Бауман урамында ятакка җәелеп яткан мәче сыны пәйда булды. Астына язу уелган – «Казан мәчесе: акылы Әстерханныкы, аңы Себернеке». Скульптор Башмаковның әсәре казанлыларга шулкадәр ошады ки, яныннан узган һәрбер кеше, «бәхеткә» дип, аның корсагын сыйпап үтә. Мырауҗанга куелган һәйкәлнең тарихы нинди соң?

Ә бөтенесе дә патшабикә Елизавета Петровнадан башланган. Галиҗәнап Казанда тычканнар булмавы турында ишеткән. Ул заман өчен сирәк бу хәл Елизаветаны бик гаҗәпләндергән, һәм ул мондый нәтиҗәгә ничек ирешү белән кызыксынган. Казанда зур башлы, итләч гәүдәле тычкан тотучы махсус мәчеләр булуы ачыкланган. Патшабикә әмере буенча, 1745 елның 13 октябрендә Санкт-Петербургка Казаннан тычкан тотар өчен утыз мәче кайтартылган. Алар, ул чакта әле төзелеп бетмәгән Кышкы сарайда урчеп, йөкләнгән вазыйфаларны үти башлаганнар. Рәсми рәвештә лейб-гвардия хезмәтенә алынган Казан кунаклары тиз арада патша сараен ул афәттән арындырганнар. XVII–XIX гасырларда аларның даны киң таралган, Албарыс дип аталган Казан мәчесе хәтта рус лубокларында сурәтләнә башлаган.

Казан мырауҗаннары салган гадәт буенча, аларның тугандашлары Елизавета заманнарыннан бирле рәсми хезмәттә саналалар һәм Дәүләт Эрмитажы бинасында яшиләр. Ел саен 1 апрельдә музей хезмәткәрләре традицион булып киткән «Март мәчесе көне» уздыралар.

«Казан мәчесе шәһәрнең рәсми булмаган символы була ала, – дип язган тарихчы Ф. Фәизов. – Мәркәзнең инде елан сурәтләнгән гербы бар, бу бик яхшы. Ләкин канатлы аждаһаның биографиясе юк, анда йорт хайванына хас җылылык җитми. Ә Казанга һәр кешегә якын була алырлык символ кирәк. Шуңа күрә аны лаеклы рәвештә пьедесталга күтәрергә кирәк».

Ниһаять, Казан мәчесен пьедесталга күтәрделәр, һәм ул Татарстанның сигез символы арасында лаеклы урынын алып тора.



Валерий ТАРАСЕНКО



Сергей АНДРИАНОВ

Язылһәм телевизор от!



1 Языл

31.12.2017 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 Җибәр

язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От

Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!

БҮЛӘКЛӘР

2018 елның 9 февралендә

УЙНАТЫЛАЧАК





Акцияне үткәрү вакыты: 25.10.2017 - 20.03.2018

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама



ВИРТУАЛЬ ГЕНСЕК

Кытайда «Си Цзиньпинга кул чап» дигән компьютер уены уйлап чыгарганнар. Уенчыга генераль секретарьнең Кытайның бөтен дөньядагы хакимлегенең 14 принцыбын һәм хәзерге социализм турында сөйләгәнен тыңларга кушыла. Сөйләү туктауга, уенчы гөрләтеп кул чабарга тиеш. Моның өчен экранда виртуаль куллар һәм Кытай компартиясенең утырыш залы пәйда була. Беренче тәүлектә генсекка 800 миллион тапкыр кул чапканнар.

ЗАМАНЧА ДИН

Элекке инженер Энтони Левандовски үзе уйлап чыгарган "Киләчәккә юл" дини тәгълиматына нигез салучы буларак танылган. Яңа диннең асылы – ясалма интеллектка нигезләнгән тәңрегә табыну. "Пәйгамбәр" хәзерге җәмгыятьнең үсеш юлын компьютер акылына табынуда күрә. Левандовски үзен баш рухани, яңа диннең президенты һәм генераль директоры дип игълан иткән.

ҖИҢЕЛҮ ТАЛӘП ИТӘБЕЗ!

Бразилиянең "Ибис" футбол клубы җанатарлары яраткан командаларының көтмәгәндә матчларда җиңүләреннән ризасызлык белдергәннәр. Бу команда беркайчан да беркемне дә отмаган булган. Рәттән дүрт җиңү фанатларның кәефен кырган. "Безнең хәзерге шигаребез – без дөньяда иң начарлар! Әгәр сез җиңә башласагыз, клуб үзенең кабатланмаслыгын югалтачак һәм башкалардан бернәрсә белән дә аерылмаячак", – дип белдергәннәр җанатарлар.

РУХИ БАЙЛЫК

Таиландта яшәүче сәясәтче һәм эшкуар Тамбон Прасерт хатын-кыз затын чиктән тыш яратуы белән дан казанган. Хәзерге вакытта аның 120 хатыны һәм 28 баласы бар икән. Тамбон һәр очракта да кәләшенең ата-анасыннан хәер-фатиха алып, бөтен гореф-гадәтләргә туры китереп туй ясаган. Бөтен гаиләләренә дә матди ярдәм күрсәтеп тора. Җирле законнар буенча, күп хатынлылык тыелган, ә аның хатыннары бер-берсен беләләр һәм бу хәлдән алар бик риза.













Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Күрәзәче яшь ханымга язмышын юрый:

– Тиздән бик чибәр брюнет белән танышырсыз һәм аның белән бер җан, бер тән булып яшәрсез!

– Һм... Бу нәрсәгә минем иремнең мөнәсәбәте ничек булыр икән, әйтә алмассызмы?

• • •

Чәчәк кибетендәге сатучыдан йөзеңне нигә сагыш сарган, дип сорыйлар.

– Әле генә моннан чыккан яшь егет ел буе үзенең сөйгән кызына миннән чәчәк сатып ала торган иде. Иртәгә аның туе, – дип җавап бирә ул.

– Шуңа боектыгызмы?

– Шундый яхшы клиентны югалтуы бик авыр.

• • •

Кечкенә малай игътибар белән ничек итеп сыерларга су эчертүне карап тора да:

– Менә ничек итеп сөткә су кушалар икән, – дип әйтеп куя.

• • •

– Хатыннар гына түгел, ирләр дә серле булырга тиеш. Ату тоталар да сорыйлар: «Өйләнгәнме? Өйләнмәгәнме?» – дип.

• • •

Күселәр капитанны корабльдән качучыларның өйрәнү тревогасы икәнен кисәтеп куйганнар.

• • •

Прапорщик:

– Музыкантлар бармы?

– Так точно!

– Пианиноны җиденче катка күтәрегез!

• • •

Полицейский:

– Аңлатып бирегез әле. Бу җәяүлене ничек итеп бәрдердегез?

– Мин аны бәрдермәдем... Үтеп китсен дип туктавым булды, ә ул гаҗәпләнүеннән һуштан язып егылды.

АЛМАЗ НИЧЕК БРИЛЛИАНТ БУЛА?..

Армиядә иң беренче тапкыр сафка тезелеп баскан көннәрен солдат гомергә онытмый торгандыр...

"Җырлый белүчеләр – бер адым алга!"
"Рәсем ясаучылар – бер адым алга!"
"Шоферлар..."
"Музыкантлар..."
"...бер адым алга!"

Кыскасы, ул көнне рядовой Хәмзин, ун адым алга чыгып, командирның каршысына ук килеп җиткән. Һәм аны шундук сержант иткәннәр...

Хезмәт итеп кайтуына, аны Рифкать Гомәров җитәкчелегендә дисталаган кыз тезелешеп каршы алган. Алмаз Хәмзинның сәнгатьтәге беренче адымнары "САЗ" ансамбле белән бергә бара. Тормыш тәҗрибәсе туплап, буй-сын ныгыткан егетнең Педагогика институтының музыка факультетын тәмамлый алуы – үзе үк тәвәккәл адым. Ул филармониябездә режиссер да, театр училищесында педагог булып та эшләде. Матурматур җырлар язды, үзе үк шуларны башкарды да... һәм сержант Алмаз Хәмзин эстрада йолдызына әверелде. Адым саен – үсеш, адым саен – үзгәреш... Ул сәхнә өчен язылган күп кенә монологлар һәм юморескалар авторы... Телевизион шоулар оештыручы, режиссер, сценарист, пародияләр остасы... Кыскасы, мондый – Алыптай адымнар белән ерак китә алмас безнең Алмаз, дисәк, ул "Чаян" журналының әдәби бүлек хезмәткәре булып урнашып өлгерде. Инде ул танылган прозаик, "Казан утлары" журналында әледән-әле хикәяләре чыга килә. "Шамкай" повесте белән сөекле абунәчеләребезнең мәхәббәтен яулап өлгерде. Мәхәббәт, димәктән, "Бармагыңнан үбәр идем" дигән хикәя дә чын сөю турында. Юмор остасы Хәмзә киракса комик та, теләсә трагик та була белә.

Тулы бер китапка исем булырлык хикәя исеме. "Кулыңны сорыйм" дими бит, бармагыңнан үбәргә дә риза ди егет. Мондый талантлы язучы тагын да кыюрак адымнары белән сөендерер әле безне.

Бирсен Ходай!

Камил КӘРИМОВ

МИН КЕМ?

Алмаз Хәмзин, диярсез.
Мин туган көнемдә
Ап-ак кулмәк киярсез!..
Миңа инде – җитмеш,
Исә сиксәннәр җиле.
Бүген сүзем үзем турында,
Ә язмышлар – күке кулында.
Күк-ку, күк-ку, күк-ку, күк-ку,
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Үә-үә үчтеки,
Бишәү, алтау, җидәү, сигез,
Ыштан кидем чүтеки.
Тугыз, ун, унбер, унике,
Нәрсә саный ул күке?
Унөч, ундүрт, унбиш, уналты,
Теге ыштан сүтелде...
Унҗиде, унсигез, унтугыз,
Ашаганыбыз – сагыз.
Егерме, егерме берләрдә
Мораль кодекс укыйбыз.
Егерме ике, егерме өч –
Армиядә без, имеш...
Егерме дүрт, егерме биш,
Иске ыштан шул килеш.
Егерме алты, егерме җиде,
Гел урысча укыйбыз.
Егерме сигез, егерме тугыз,
Бар белгәнем – кукуруз.
Утыз, утыз бер, утыз ике,
Кәнкәйде теге күке.
Утыз өч, утыз дүрт, утыз биш,
Интектерде бит "төлке".
Утыз алты, утыз җиде,
Капитализм җиңде.
Утыз сигез, утыз тугыз,
Ашыйбыз гел
Анкл бэнс.
Кырык, кырык бер, кырык ике
Саный безнең гомерне.
Кырык өч, кырык дүрт,
кырык биш,
Инде ничәнче күке?
Санама, күке, санама,
Алмазга инде җитмеш.
Тиле күкеләр иләндә
Гомерләр үтеп китеш.
Соңгы "күке" әйтте:
"Сколько хотите – столько
Проглотите!" – диде.
Алдагы күке алдады
Сине, мине, илне, Ходайны.
Шуңа күрә йота алмыйм
Учымдагы шушы бодайны.
Мин кем?
Алмаз Хәмзин, диярсез.
Минем туган көнемдә
Ап-ак күлмәк киярсез.
Миңа инде җитмеш,
Исә сиксәннәр җиле.
Соңгы сүзем Сезнең турыда,
Ә язмышлар – күке кулында
Күк-ку!..

Рәшат **НИЗАМИ**

АРКАДАШ ДУСТЫБЫЗГА

"Син шагыйрь!" – диеп мактагач,
Мин инде тәмам аздым:
Юбилей мөнәсәбәте илә
Шушы шигырьне яздым...
(Эпиграф урынына).

Кемнәр сиңа белеп кушты икән
"Алмаз" дигән затлы исемне?
Энҗе-мәрҗән итеп чәчә белдең
Тапкыр сүзне, җырны, хисеңне.

Яшьлек дәрте синнән ташып тора,
Исемеңне, шөкер, акладың.
Таш яуса да, сәхнә түрләренә
Егет булып һәрчак атладың.

Исемеңә җисмең туры килә:
Күпкырлы син – алмаз ташыдай.
Көй язасың, ай-һай, булдырасың –
Илһам чишмәң тулып ташыган!

Үзең аек, ә җисемең лаек
Алмаз дигән күркәм исемгә.
Син тугансың, ахры, кешеләрне
елатырга түгел,
Бары елмайтулар өченгә.

"Кеше көлдермә...", –
дип озаткан әткәң,
Әманәтен дөрес аңладың:
Кешеләрне көлдерсәң дә, үзең –
Кеше көлкесенә калмадың!

Әйтелмәгән өр-яңа сүз көтеп,
Тамашачы сиңа текәлгән...
Чуп-чар "үләннәр"не күп йолкыдың
Тормыш дигән чуар түтәлдән.

Һәр концертың йомры сүзләр белән,
Дәртле җырың белән башланды.
Айга менсәң, син анда да хәтта
Елмайтырсың кебек ташларны!

Бәрхет тавыш белән син сөйлисең,
Тамашачы карый "аһ!" итеп.
Ничә тапкыр сиңа кидерделәр
Яровойның
Өркетергә тиеш "пакет"ын...

Син сазыңны ярты юлда өзеп,
Тукталмадың, шартлап сынмадың.
Татар йөрәгенә сибә белдең
Татарымның үлмәс моңнарын!

Түбәтәең бик килешле сиңа,
Йөзең нурлы, үзең шаян да.
Әле дә булса, җир җимертеп, әнә,
Эшләр майтарасың "Чаян"да.

Шагыйрь сүзен файдаланып әйтәм:
Гармуныңны, әйдә, тарт, дустым, –
Атлыйк әле ЯШЬЛЕК урамыннан,
70 яшь ул нигә карт булсын?!.



СИМФОНИЯ

Көтмәгәндә авылдан кордаш Мәҗит килеп төште. Нәрсә булды икән тагы? Ул шулай бер-бер нәрсә булса, ялт итә дә минем янга килеп чыга. Әле үткән ел гына, сырты кычыта башлаган кешедә рак авыруы булырга мөмкин дигән сүзгә ышанып, тинтерәтте мине. Таныш врачларыма күрсәтеп йөрдем үзен. Бернәрсә дә юк. Тегене котыртканнар гына. Юкка-барга бик тиз ышанучан. Үткән атнада тагын булып китте. Бу юлы инде, колак эченә йон үсә башласа, СПИД йоккан булуы мөмкин дигән сүзгә ышанып килгән. Авыл шаяннары моның колагы эчендә берничә бөртек йон күргәннәр дә, СПИД дигәннәр. Моңа җитә калган, бу – тагын минем янга!.. Тагын бүлнис юлын таптадык. Анализлар тапшырып дигәндәй. Инде менә тагын килеп җиткән. Кемнәндер: "Синдә простатит авыруы", – дигәнне ишеткән. Анысы, мәйтәм, дүрт ирнең өчесендә бар инде. Миндә дә бар ул. Менә яшим бит әле, Аллага шөкер.

Хатын-кызга күз төшми башлады ди бу. Мин дә шулай, мәйтәм. Борылып та карамыйм. Курыкма, үтерми ул! Тынычланды бугай. Кичкә таба икебезгә бер яртыны бөкләдек тә, Зур концерт залына симфония тыңларга киттек. Хатын белән барырмын дип алып куйган билет бар иде. Кунак хөрмәтенә хатын бармаска уйлады.

Утырабыз кордаш белән симфония тыңлап... Әй, шаккатты инде: симфониянең көчәеп киткән чагында тракторының пускач бавын тартканнан соң чыккан колак ярырдай тавышын тизрәк басарга тырышкан хәрәкәтләр ясый, көй тынып калган чагында күршесе Мәликәнең ишегалдында йөрүен койма ярыгыннан тын да алмыйча карап торган сурәтләргә керә. Музыка тизләгәндә, көтүдән качкан сыерын куалагандай чапкан, әкренәйгәндә хатыны Сәриянең кухнясыннан салмак кына атлап чыгып, алдына аш китереп куйган мизгелләр төсмерләнә...

Менә сәхнәгә оркестрга кушылып җырлаучылар да чыга башлады. Петр Ильич Чайковскийның "Мазепа" операсыннан Мазепа ариозасын Россиянең атказанган артисты Павел Черных башкара. Мәҗит кордаш, кашларын җыерып, бу урыска карап-карап торды да: "Үгез!" – дип куйды. Әйе шул: аның җырлавы урам буйлап улап килүче нәселле үгез мөгрәвен хәтерләтә. Авыл халкы булса, капкаларын бикләп, ишегалларына качып бетәрләр иде. Мәҗит як-ягына каранып алды. Юк, берәү дә качмый. Түзәләр.

Черныхны үзебезнең филармония җырчысы Наилә Сәгыйрова алыштырды: ап-ак күлмәктән – аккошмыни! Күрәм, кордашның күзләре елтырый башлады. Тик Наиләнең җыры гына татарча булып чыкмады. "Аве Мария"не башлавын ишеткәч, Мәҗит иң элек пошынган иде дә, соңыннан дөньясын онытты. Наилә аның Сәриясенә охшаган. Дулкынлана кордаш. Маңгаена тир дә бәреп чыкты. Сул кулы белән ялгыш минем ботны каптырып алды...

Ярый әле Наилә берне генә җырлап кереп китте. Кордаш белән нәрсә булып бетәсен шайтан белгән... Сәхнәгә, бик зурлап, Бельгиянең милли опера җырчысы Ольга Чеснокованы чыгардылар. "Безнеңчә – Сарымсакова! – дип өстәп куйды Мәҗит. – Бик нык уңган бу", — дип тә сылады кордаш, марҗаның юанлыгына ишарәләп.

Минем үз каланчамнан караганда, әйбәт җырлый марҗа, сүз әйтерлек түгел. Тик кордашка ул ошамады, күрәсең. "Пьяновка авылында урыслар дуңгыз суямыни!" – дип җырны чинауга тиңләде.

Айдар Фәйзрахмановның фольклор ансамбле чыккач, Мәҗит канатланып китте. "Зерә, – ди бу миңа, – гармунны алып килмәгәнмен, чыгып уйный идем, билләһи". Кызды кордаш, урынында биеп утыра. Янәшәдәгеләрдән уңайсыз, ләкин сүз әйтүче юк. "Безнекеләр уздыра", – диде ул, ансамбль кереп киткәч. Инде кем чыгар икән?

Күрәм, Резеда Галимовабыз! "Моя прекрасная леди" опереттасыннан Элиза Дулитл җыры. Мәҗит кордаш авызын ачып катып калды. Яп, мәйтәм, төкерек савытыңны! Кайткач, хатыныңа әйтәм. Белмим, тагын нинди хыялларга күмелгәндер Мәҗит. Алсу күлмәкле Резеданең ярты ачык гәүдәсе минем дә тирән һәм саф хисләремне уятты, күрәсең. Күңел томанланды. Сихри моң мине дә әллә кайларга алып китте.

...Ак каеннар арасында алсу күлмәкле кызлар тулган. Кайсысы минеке?..

Шул вакыт идәнгә кемнеңдер чалбар төймәсе тәгәрәгәне ишетелде. Сискәнеп, хисләремнән айнып киттем. "Кемнеке?" – мәйтәм. "Минеке", – ди Мәҗит. Карт җүләр, сиңа алтмыш тулып килә түгелме соң?

Тирә-юньдәгеләр пырхылдап куйды. Ярар, бу турыда онытып торыйк. Бер айдан соң яңадан Зур концерт залына симфония тыңларга бардым. Халык өстенә халык! Брәрәч, гел безнең авыллар гына түгелме соң монда? Әйе шул, әнә Мәҗит йөри, Рәхим абый да килгән, 80 яшьлек Сахбый да калмаган. Простатит дәвалыйлар икән...





Ринат МИРЗАЯНОВ



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 11 (1865) ноябрь 2017

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы җитәкчесе һәм баш редактор Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Р. АБЗАЛОВ**

Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **А. АЛЁШИН**

Үсеш бүлеге: **П. СТАРОВЕРОВ**

Җаваплы секретарь: **Г. ЗАМАЛДЫНОВА**

Бүлек редакторлары: **Л. САФИУЛЛИНА, А. СУББОТКИН, А. ХӘМЗИН, Л. ӘХМӘТОВА, Г. СӨНГАТУЛЛИНА,**

Дизайнер: **Л. ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**

Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

«Чаян»га Татарстанда, Россиядә һәм БДБда барлык элемтә бүлекчәләрендә һәр айдан язылырга мөмкин.

Татарстанда яшәүче укучыларыбыз журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар. Бу очракта язылу индекслары русча П2440, татарча П2438. «Агентство «Роспечать» Каталогында индекслар: 73489 – рус, 73488 – татар телендәге журнал өчен. Аның буенча Россия һәм Татарстан укучылары язылa ала.

Айга бер тапкыр чыга.

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килмәскә мөмкин.

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.

«Чаян»нан икәнен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.

Басарга кул куелды: 1.11.2017 ел.

Гомуми тираж –3210 (рус. – 1918, тат. – 1292)

Заказ А-2784

Кәгазь форматы 84х108 1/16.

Офсет ысулы белән басыла.

Басма табагы 2,1.

Учетн.-изд. табагы 3,1.



татмедиа

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, тел./факс: 222-05-54.

16+

E-mail: chayan@bk.ru

Сайт: chayan-journal.ru

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Бәясе ирекле

Көтелгән Концерт

("К" хәрефенә күнекмә-тавтограмма)

Күптәннән көтелгән концерт-конкурста күпләр катнашты.

Конкурс караучылар Каракалпакстаннан каравылчы Кыпчакбай Кырамбеков, Кипрдан киномеханик Ксенос Киприану, Казаннан комик Кабил Кәбировның кыланышларыннан корсаклары катканчы көлде.

Кабартылган күкрәкчә кигән конферансье, конкурс күзәтүчеләрне кинәндереп, клиптагы Королёвадай кыланды.

Кукмара китапханәчеләре Кант күптомлыгы китапларыннан километрлы конус кордылар.

Кавказдагы Кисловодск каласыннан килгән көтүче кабардин Кулан Кадырханов күн камчы кулланып, клубтагыларны куркытты: кычкыра-кычкыра күй көтүе, көнгерәләр куды.

Котлыбөкәш кладовойчысы Котдус Касыймов келәт киштәләренә кысып, кыз-кыркыннарны кочаклау күренеше күрсәтте. Концерт караучы кызларның күңелләре кителде кебек...

Кояшта кара көйгән кыргый Конго кабиләләре какаду каурыйларыннан киселгән курайда Киншасада күйгән концертларыннан каприччо көйләделәр.

Кытай кулинарлары кымыз, кара карлыган, киптерелгән күбәләк канатларыннан коктейль күпертеп күрсәттеләр.


Көньяк Кореядан килгән Ким Кио кыздырган кишер, көнбагыш кабыгы кушылган карабодай камырыннан коймак койды. Күбрәк киткән коймаклар караучыларны кызыксындырмады, Кимнең күңеле кителмәсенгә көлгәндәй кыландылар.

Кыргызстан концертмейстеры Колжегет Кылычбәкевнең каешланган киез калпаклар кигән "Кыргыз көе — кешелек канаты" квинтеты кырык кыллы комуз кыңгырдатып, күпне күргән Киркман клавесинын кычкыртып, конкурс караучыларның күңелләрен канатландырды.

Кызыл крепдешин күлмәкле Кәләй керәшеннәре күрмәгәнне күрсәтте: кара кашлы, кызгылт-көрән күнитекле кызлар кордебалет келтерәттеләр, кытыршы куллы картлар контрафагот, кларнет, кубызда Коуэллның каты какофониясен көйләде, карчыклары кызыл капрон колготки, кара күн курткалар киеп, киек казлар кебек канат кагынды...

Концерт караучыларның күңелләре күккә күтәрелде...

Ринат АБЗАЛОВ



СӘЕР КЕШЕЛӘР

Валентин ДРУЖИНИН




Сергей ЕРМИЛОВ



Илдус АЗИМОВ





Илдар НӘФИЕВ



